**ГЛАВА**
**Кадряковского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кадрәк авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2024 Кадрәк авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Кадрәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Кадрәк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын 2024 елның 28 октябрь көнне 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы "Кадрәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Кадрәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар (80 яшькә җиткән), студентлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле рәвештә китканнәрдән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (аларның ата-аналарын, хатыннары, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итеп һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне үтәү буенча алынган мәсьәләләрне хәл итүгә юллап, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдереп, гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: 2025 елда үзара салым акчасын 700 сум күләмендә кертү һәм куллану белән килешәсезме?":

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кадрәк авылының Ленин,

Нарат, Полевая, Заречная, Яшьләр урамнары өчен вак ташлар сатып алу һәм салу);

- торак пунктлар чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр өчен җир өсте юлларын ремонтлау (Кадрәк авылы чикләрендә күперләрне ремонтлау һәм карап тоту);

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә түләү);

- электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау (лампаларны, дроссельләрне, фонарьларны сатып алу һәм урам яктырту өчен материаллар сатып алу);

- халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү, аларга якын урнашкан торак пункт территорияләрен төзекләндерү (Ленин, Полевая, Яшьләр, Заречная, Нарат урамнарында юлларны кардан чистарту), тракторны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, мәдәният йорты, ФАП, административ бина коймаларын ремонтлау, төзекләндерү буенча башка чыгымнар;

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (сантехник һәм башка чыгым материаллары сатып алу һәм су белән тәэмин итүнең башка чыгымнары).

*«РИЗА»* *«КАРШЫ»*

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кадрәк авылы, Ленин ур., 55 нче йорт, авыл мәдәният йорты территориясендә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә, «Интерне» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы А.А. Михайлов

Совет Кадрәковского сельского поселения
Кадрәк авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002558